| | |
|---|---|
| СОВЕТ КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
| 24.10.2022 | д. Канаш | №20-117 |

Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен
гамәлгә ашыруда катнашу турында

Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренең 37 статьясы нигезендә",

Югары Ослан муниципаль районының
Канаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары Канаш авыл җирлегендә, торак пунктта яшәү урыны яисә булу урыны буенча теркәлгән затлар өчен түбәндәге нотариаль гамәлләрне башкарырга хокуклы, дип билгеләргә:

1) кучемсез мөлкәт белән эш итүгә ышанычнамәләрдән тыш, ышанычнамәләрне расларга;

2) документларның күчермәләренең һәм аларның өземтәләренең дөреслеген исбатларга;

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Вальков